**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвалидлар эшләре советы составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвалидлар эшләре советын төзү турында» 2010 елның 31 декабрендәге ПУ-908 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 30 апрелендәге ПУ-247 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2016 елның 2 сентябрендәге ПУ-786 номерлы, 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2018 елның 14 маендагы ПУ-369 номерлы, 2019 елның 2 февралендәге ПУ-59 номерлы һәм 2019 елның 21 августындагы ПУ-479 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Инвалидлар эшләре советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан А.Р. Зариповны чыгарырга;

б) Совет составына Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улын – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен кертергә;

в) Совет әгъзасы Р.Ш. Ганибаевның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең «Татарстан Республикасы инвалидлар җәмгыяте» Татарстан республика оешмасы рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 25 ноябрь
№ ПУ-707